ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2024 Мөслим ав. № 97

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм дәүләт торак программалары буенча торак урыны бирү нормасы турында» 2006 елның 08 сентябрендәге 157 номерлы карары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 маддәсе һәм «Торак базарын тикшерү турында» 2024 елның 06 февралендәге 40 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» ПН хаты нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь әһәмияте:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 21086,77 сум;

1.1.2. ике кешелек гаиләгә: һәр гаилә әгъзасына 13418,85 сум;

1.1.3. өч һәм аннан күбрәк кешенең гаиләсенә: һәр гаилә әгъзасына 11501,87 сум

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме түбәндәгеләрне тәзи:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1066890,00 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 1357860,00 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 1745820,00 сум;

1.2.4. Дүрт кешелек гаилә өчен – 2327760,00 сум

1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 2909700,00 сум;

1.2.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 3491640,00 сум;

1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 4073580,00 сум;

1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен - 4655520,00 сум.

2. Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенә
Мөслим муниципаль районының 1.1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күрсәткечләрдән файдаланып, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда файдаланырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча

Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Д.З. Мөхәммәтдиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 28 февралендәге
97 номерлы карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү**

Торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган муниципаль берәмлекләрдә һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) *кп) / (0,25 х РС), анда

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) (2024 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека торак кредиты буенча уртача үлчәү ставкасы елына 7,75%, ягъни айга 7,75/100/12=0,006);

КП - кредит буенча барлык срокка түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2024 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека торак кредитлавы буенча уртача үлчәү срогы 313 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

«Торак базарын тикшерү турында» 2024 елның 06 февралендәге 40 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» 1111 хаты нигезендә, 2024 елда Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 32330,00 сум тәшкил итә.

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү

| НП - Т.у бәясе торак га (кв. м) | СЖ- Торак сат алу бәясе (СЖ = РС Х РЦх НП) (сум) | РС - гаилә әгъз.саны (кеш.) | РЦ- базар бәя 1 кв. торак урын (сум) | ПС - процент ставка бер ай эчендә кредит (уртача еллык - 7,75%) (7,75/100/12) | КП- Кред түләүләр (ай) | фатир бәясе кредит суммасы нисбәте | кредит буенча түләү нисбәте тулаем гаилә айлык керем(0,25*Р С) | ПД - макс керем күләме (сум) (кеше) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | л I | 4 | 5 | 6 | 8 | 9 | 9 |
| 33 | 1066890,00 | 1 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 0,25 | 21086,77 |
| 42 | 1357860,00 | 2 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 0,5 | 13418,85 |
| 54 | 1745820,00 | *3* | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 0,75 | 11501,87 |
| 72 | 2327760,00 | 4 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 1 | 11501,87 |
| 90 | 2909700,00 | 5 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 1,25 | 11501,87 |
| 108 | 3491640,00 | 6 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 1,5 | 11501,87 |
| 126 | 4073580,00 | 7 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 1,75 | 11501,87 |
| 144 | 4655520,00 | 8 | 32330,00 | 0,006 | 313,0 | 0,7 | 2 | 11501,87 |